**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **20.11.2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Югары Стәрле авыл жирлегенэ
керүче Түбән Стәрле авылында 2020 елда
үзара салым жыюны кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегендә халык җыены карар бирэ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл жирлеге Түбән Стәрле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300.00 (өч йөз) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 группа инвалидлар өчен 150 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү:

- Түбән Стәрле авылында Кызыл тан урамынын юлларына щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Түбән Стәрле авылында юлларны кардан чистарту;

- Түбән Стәрле авылында территорияләрне чүп үләннәреннән һәм чүп-чардан чистарту хезмәтләре;

- бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Инвалидлар көне», «Яңа ел " бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү».

3. Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Югары Стәрле авылы, Совет., 32г йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Югары Стәрле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче.

Югары Стәрле авыл җирлеге башлыгы: Сабиржанова Л.С.